| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА<br>ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ САБИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.09.2024 № 737-п

Саба муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 25 маендагы 706-п номерлы карары белән расланган милеккә арендалана торган милек сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 6 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 маендагы 706-п номерлы карары белән расланган милеккә арендалана торган милек сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

**1.1.** 2.8.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4) пунктча өстәргә:

"4) мөрәҗәгать итүченең «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясында билгеләнгән арендалана торган мөлкәт сатып алуга өстенлекле хокук шартларына туры килмәве"

**2.** Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча игълан итәргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе М. Р. Ишниязов